Кукмара муниципаль районының
Югары Чураавыл башкарма комитеты

Карар

«15»февраль 2021 ел №2

Югары Чура авыл башкарма комитетының 2020 елның 01 октябрендәге 19 номерлы карары белән расланган Агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кисүгә яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 2020 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын фаразланган үтәү йомгаклары һәм республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга бурычлары буенча уртак коллегиясенең Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан 2021 елның 04 гыйнварында (№ ПР-3) имзаланган 24 нче пунктын үтәү йөзеннән карар бирәм:

1. Югары Чура авыл башкарма комитетының 2020 елның 01 октябрендәге 19 номерлы карары белән расланган Агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кисүгә яисә утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2.5 пунктына түбәндәге эчтәлекле 9 нчы пунктчаны өстәргә:

«9) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычларның булмавы турында салым органына белешмә. Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турындагы белешмә авария хәлендәге хәлләргә бәйле очраклар өчен бирелми».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

Югары Чура авыл
башкарма комитеты җитәкчесе И.Н. Алексеев